КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 11 май г.Казань № 431

«Татарстан Республикасының электрон сәламәтлек саклавы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Сәламәтлек саклау» илкүләм проекты кысаларында расланган «Сәламәтлек саклауның бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә сәламәтлек саклауда бердәм цифрлы контурны булдыру» төбәк проекты күрсәткечләрен үтәү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Татарстан Республикасының электрон сәламәтлек саклавы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – Система) турындагы нигезләмәне расларга.

2. «Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә Системаны эксплуатацияләү һәм үстерү функцияләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» автоматлаштырылган системасын «Татарстан Республикасының электрон сәламәтлек саклавы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы итеп билгеләү турында» 2021 ел, 13 октябрь, 972 нче карары нигезендә гамәлгә ашырырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер–министры А.В.Песошин